# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Биләр авыл җирлеге составына керүче
Шәмә авылы торак пунктында

2020 елның 12 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге составына керүче Шәмә авылы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда Биләр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
 - авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, юл кырыйларындагы үләннәрне чабу);
 - авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү;
 - җирләү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (аварияле агачларны кисү һәм җыештыру, килешү буенча түләү)
 - тракторны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы);
 - күпер һәм җәяүлеләр кичү юлларын карап тоту һәм ремонтлау;
 - суүткәргечне ремонтлау.

3. Әлеге карарны Биләр авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Шәмә авылы, Елга аръягы урамы, 17 нче йорт адресы буенча урнашкан Шәмә мәдәният йорты бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Г.Г.Хәбибуллин